ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш, Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш., Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 100 от «12» 03 2021 г.

«2020-2022 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында Физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«2016-2020 елларга Россия Федерациясендә физик культураны һәм спортны үстерү» федераль максатчан программасы, «2014-2021 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культураны һәм спортны үстерү» дәүләт программасы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 27 апрелендәге 163 нче карары белән расланган «2020-2022 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасына ( 13.11.2020 ел, 396 нчы карардагы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

- «2020-2022 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасыны Паспортындагы «Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» бүлеген 1 нче кушымтадагы редакциядә бәян итәргә.

- 2020-2022 елларга Мамадыш муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү буенча чаралар турында:

- 5 нче санлы «Матди-техник базаны үстерү» бүлегендә 5.6 пунктка төзәтмәләр кертергә, 5.9 пунктны өстәргә;

- 6 нчы санлы «Спорт төрләрен үстерүдә өстенлекләр» бүлегендә 6.3 пунктка 2 нче кушымта нигезендә төзәтмәләр кертергә.

2. Әлеге карарны Интернет-телекоммуникация челтәрендә Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru/ рәсми сайтында веб-адрес буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.Р.Хуҗаҗановка йөкләргә.

Җитәкче И.М.Дәрҗеманов

0000010819

Татарстан Республикасы
Мамадыш
муниципаль районы
Башкарма комитетының
12.03.2021 ел,
№ 100 санлы карарына
1 нче кушымта

| | |
|---|---|
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Программаны финанслау Мамадыш муниципаль районы бюджеты, бюджеттан тыш чыганаклар, билгеләнгән тәртиптә җирле бюджетка бүлеп бирелгән күләмдә республика бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырылачак:<br>2020 ел - 64 830,1 мең сум.<br>2021 ел - 68 753,5 мең сум.<br>2022 ел - 69 527,9 мең сум.<br>шул исәптән республика бюджеты:<br>2020 ел- 210,1 мең сум (спорт инвентаре)<br>2021 ел- 231,5 мең сум (спорт инвентаре)<br>2022 ел- 214,5 мең сум (спорт инвентаре)<br>2021 ел – 346,9 мең сум (хоккей буенча программаларны тормышка ашыруга)<br>2021ел – 100,0 мең сум (яңа ачылган спорт объектларына спорт инвентаре алу өчен) |

Татарстан Республикасы
Мамадыш
муниципаль районы
Башкарма комитетының
12 03 2021 ел,
№ 100 санлы карарына
2 нче кушымта

## 5. Матди-техник базаны үстерү

| № | Чараларның эчтәлеге | Үтәү вакыты | Үтәлеш өчен җаваплы | Финанслау күләме (мең сумнарда) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2020 | 2021 | 2022 |
| 5.6 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе нигезендә муниципаль физкультура спорт оешмаларын җиһазландыру өчен спорт җиһазлары, экипировка һәм инвентарь сатып алуга бюджетара трансфертлар (республика бюджеты) | 2020-2022 еллар | «Хоккей һәм физик культура буенча спорт мәктәбе» МБУ «Олимп» спорт мәктәбе» МБУ | 210,1 | 231,5 | 214,5 |
| 5.9 | Бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе нигезендә яңа ачыла торган спорт объектларын җиһазлар һәм инвентарь белән тәэмин итүгә (республика бюджеты). | 2021 ел | «Олимп» спорт мәктәбе» МБУ | 0 | 100 | 0 |

## 6. Спорт төрләрен үстерүдә өстенлекләр

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 6.3 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, «ХиФК» СШ " МБУ спорт командаларының хоккей буенча Татарстан Республикасы чемпионатында (республика бюджеты) катнашуы һәм спорт әзерлеге программаларын гамәлгә ашыру өчен бюджетара трансфертлар. | 2020-2022 еллар | «Хоккей һәм физик культура буенча спорт мәктәбе» МБУ | 590,2 | 346,9 | - |